ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТҮБӘН СУЫК-СУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

КАРАР

13 март 2026 ел Түбән Суыксу авыл № 2

2025 ел өчен Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап проекты буенча халык тыңлауларын үткәрү хакында

Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге халкының «2025 ел өчен Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап» хакында карар проекты буенча фикер алышуда катнашу хокукларын саклау максатыннан, 1998 елның 31 июлендәге 145-ФЗ санлы Россия Федерациясе Бюджет кодексына, Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлегендә халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә таянып

КАРАР БИРӘМ:

1. «2025 ел өчен Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап» хакында Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Советы карар проекты буенча халык тыңлауларын үткәрергә.

2. Әлеге карарны авыл җирлегендә мәгълүмати стендларда һәм Тукай муниципаль районның рәсми сайтында 2026 елның 13 марттан да соңга калмыйча урнаштырырга.

3. Билгеләргә

- үткәрү срогын – 1 көн;
- үткәрү вакытын – 2026 елның 23 март 10.00 сәгатьтә;
- үткәрү урынын – Тукай районы, Түбән Суык-Су авылы, Үзәк урамы, 1А йорты (Түбән Суык-Су авылының мәдәният йорты, тамашачылар залы);
- фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тәкъдим итү, чыгыш хокукы белән халык тыңлауларында катнашу өчен гаризалар бирү адресын – Тукай районы, Түбән Суык-Су авылы, Мәктәп урамы, 1А йорты, (эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 16.00 сәгатька кадәр);
- чыгыш ясау хокукы белән халык тыңлауларында катнашу өчен гаризалар бирү вакыты 2026 елның 23 мартка кадәр.

4. Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Башкарма комитетына билгеләнгән тәртип нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән срокларда «2025 ел өчен Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап» хакында карар проекты буенча халык тыңлауларын әзерләргә һәм үткәрергә.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Түбән Суык-Су авыл җирлеге Башлыгы А.Р.Зарипов